КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 июль г.Казань № 540

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы территориясендә «Габдулла Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортының транспорт чараларын вакытлыча куеп тору һәм аларның хәрәкәтен җайга салу өчен өстәмә урынлы автомобиль юлы» объектын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII1 башлыгы, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә «Габдулла Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортының транспорт чараларын вакытлыча куеп тору һәм аларның хәрәкәтен җайга салу өчен өстәмә урынлы автомобиль юлы» объектын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алына торган җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенә алмаштыру юлы белән Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:24:160303:4359 кадастр номерлы, 146 605 кв.метр мәйданлы, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган, «АК БАРС – Горизонт» ябык пай инвестиция рентлы фонды (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) милкендә булган, кушымтада күрсәтелгән, 55 872 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы Олы Кабан авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлегенең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләгәннән соң, 30 көн эчендә җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

шартнамә төзүне;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган шартнамә законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы территориясендә «Габдулла Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортының транспорт чараларын вакытлыча куеп тору һәм аларның хәрәкәтен җайга салу өчен өстәмә урынлы автомобиль юлы» объекты буенча территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2024 елның 7 мартындагы 38/о номерлы боерыгы белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты нигезендә 16:24:160303:4359 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне;

алына торган җир кишәрлегенең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин